

Анвәр Джиган улы Кутуев 1929 елнын 15 июлендә Ельники районынын Чурино авылында Джиган Камалетдин улы белән Магирә Хосәен кызынын кvпбалалы гаиләләрендә туа. Гаиләдә ин олы бала булган Анвәргә 12 яшь тулганда Боек Ватан сугышы башлана. Әтисе Джиган Камалетдин улын сугышка алалар һәм тормышнын ачысын шул вакытта ук язма героебыз да татый башлый.

Анвәр Джиган улы Кутуев оныгына, Диляра Юсуповага шулай сойләгән:
- 1941 елнын августында әтием батырларча вафат була. Мин аны бvтән кvрмәдем. Похоронка 2 елдан сон килде. Анда әти Смоленск янында, Ельня шәһәрендә һәлак булган дип язылган иде. Барысы да еладылар, әни ботен урамга елады. Ул чагында мин vзем барлык фашистларны vтерергә әзер идем. Без, яшьтәшләребез белән, vз теләгебез белән фронтка китәргә жыенган идек, ләкин ике-оч кон эчендә акыл остен чыкты: кемдер йортта хужа булып калырга тиеш иде бит. Мин – гаиләдә ин олкәне идем, ике братым һәм ике сенелем кечерәк иделәр…
Биш балалалы гаилә иле ни кvрә, болар да шулай яшиләр: әнисе Магирә Хосәен кызы колхозда эшләгәнгә, Анвәр дә колхоз эшләрендә була. Унике яшьтән кvрә башлаган авырлыкларны искә тошергәндә бvген дә дулкынлана ул: авыр, ачы хатирәләр анын кvнелен борчый. Һәм Анвәр Джиган улы истәлекләрен дәвам итә: “Авылда калган кешеләрнен барысы да намус белән эшләделәр. Без, балалар, әтиләребез урынына хезмәт вахтасына бастык. Мин атта эшләдем: колхозда печән жыештырдым, ташыдым, тирес чыгардым, колхоз терлекләрен ашаттым һәм эчерттем. Әмма ин жаваплы - ашлыкны кабул итv пунктына чыгару иде. Бер грамм да югалту юк, барысы да фашист Германиясен жинv очен барды бит!
Елдан-ел хәлләр авырайды. Бәрәнге утырту очен яшелчә бакчасын сорергә кирәк иде - без дә сорә идек. Әни һәм яшьтәш яшvсмерләр жигелгәннәр, аларнын ойләрендә дә

олылар булмаган. Алты-жидешәр кеше сукага жигелеп, яшелчә бакчаларын сорә идек. Иртәдән алып тонгә кадәр шулай. Никадәр кvбрәк эшләсәк, Ватанга файда китерсәк, газаплар шулкадәр тизрәк бетәр һәм без жинәрбез, дип ышана идек. Шулай килеп чыкты да - Боек Жинv килде!

Аннары Анвәр Джиган улы Акчеево мәктәбендә жиде классны тәмамлый. Оч ел Дальний Востокта связь баталионында хезмәт итә. Туган Чурино авылына кайткач, бригадир иттереп куялар. Тырышып бар эшне дә башкара. Эшкә жаваплы, жиренә житкереп башкаручы, табигатьтән сәләтле Анвәрне “Якты тормыш” колхозы парторгы иттереп сайлыйлар. Ике созыв Акчеево авылы Советы председателе була. Лаеклы ялда, пенсиядә чакта “СССРга 50 ел” колхозында ревизия комиссиясе председателе булып хезмәт итә. Тормыш иптәше Алия Ибрагим кызы белән 67 ел бергә яшәгәннәр (Алия Ибрагим кызы оч елдан артык элек бакыйлыкка кvчкән), дvрт бала – Халиль, Кярим, Камиль, Рашидне vстергәннәр. Алия Ибригим кызы гомере буе авылы колхозы бозауларын караган. Анын оендә һәрвакыт жылы, чиста, татлы татар ашлары исләре анкып торган. Бvген Джиган улы Анвәр матур гына vлында яши. Аны алты оныгы һәм жиде оныкчыгы унышлары белән соендерә.

Үткән атнада тыл хезмәтчәне, Хезмәт ветераны Анвәр Джиган улы Кутуевка Ельники районы житәкчесе Юрий Алексеевич Бекешев “1941-1945 еллардагы Боек Ватан сугышында Жинvгә 80 ел” медален тапшырырга килгән. Ул: “Хормәтле Анвәр Джиган улы! Сез барлык буыннар очен якты vрнәк булып торасыз, Боек Ватан сугышынын авыр елларын кичердегез, уртак жинvгә зур шәхси олеш керттегез. Сезнен тормыш юлыгыз һәрберебез очен Ватанга намуслы хезмәт итvнен ин яхшы vрнәге. Илебез файдасына хезмәт иткәнегез очен рәхмәт. Сезгә нык сәламәтлек һәм якыннарыгызнын кайгыртуында, мәхәббәтендә озын гомер итvегезне телим.”

Хезмәт ветераны исеменә әйтелгән мактау сvзләре Анвәр Джиган улы кvнеленә хуш килә һәм рәхмәтләрен белдереп болай ди: “...мин онытылмаган, Ватаныма бvген дә кирәк. Хәтта ун елга яшәреп киттем...”

**Наилә НАСЫРОВА**